Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLIV-10**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 22 июле

“Мәдәният” милли проектын тормышка ашыру турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башлыгы докладында хакында

Мәдәният инфраструктурасын үстерүнең сыйфат ягыннан яңа дәрәҗәсен тәэмин итү, милләтнең иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Мәдәният” милли проектын тормышка ашыру турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башлыгы докладын игътибарга алырга.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге”нә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә тәкъдим итәргә:

- “Мәдәният»” милли проектын гамәлгә ашыру буенча “Юл картасы” эшләү;
- клуб тибындагы мәдәни-ял итү оешмаларын реконструкцияләү;
- мәдәният тармагы өчен кадрлар әзерләү;
- музыкаль сәнгать өлкәсендә талантлы яшьләрне алга этәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов